# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

## КАРАР

«29» 07 2024 ел Яр Чаллы шәһәре № 3429

«2015-2026 елларга Тукай муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру» программасын раслау турында» Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2014 елның 26 декабрендәге 7132 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында коррупциягә каршы көрәш турында» 2006 елның 04 маендагы 34-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «2015-2025 елларга Татарстан Республикасының коррупциягә каршы сәясәтен гамәлгә ашыру» дәүләт программасын раслау хакында» 2014 елның 19 июлендәге 512 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 03.10.2015 № 741, 20.02.2016 № 104, 26.05.2016 № 354, 09.11.2016 № 832, 26.05.2017 № 311, 26.03.2018 № 174, 10.09.2018 № 763, 17.06.2019 № 495, 16.09.2019 № 837, 25.12.2019 № 1201, 01.06.2020 № 451, 09.09.2020 № 814, 25.03.2021 № 169, 17.06.2022 № 577, 18.09.2023 № 1150, 31.05.2024 №390 карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) нигезендә Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты

## КАРАР БИРӘ:

1. «2015-2026 елларга Тукай муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру» программасын (алга таба – Программа) раслау турында» Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2014 елның 26 декабрендәге 7132 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. карарның исемендә «2015-2026 еллар» сүзләрен «2015-2027 еллар» сүзләренә алыштырырга;

1.2. «2015-2027 елларга Тукай муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру» муниципаль программасын кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны районның рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе А.Р. Хәбибуллин

Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 29 июль 3429 номерлы карарына кушымта

**«2015-2027 елларга
Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру»
муниципаль программасы**

**Муниципаль программа паспорты**

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | «2015-2027 елларга Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру» муниципаль программасы (алга таба – Программа) |
| Программаны эшләү өчен нигез | «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында коррупциягә каршы көрәш турында» 2006 елның 04 маендагы 34-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «2015-2025 елларга Татарстан Республикасының коррупциягә каршы сәясәтен гамәлгә ашыру» дәүләт программасын раслау хакында» 2014 елның 19 июлендәге 512 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 03.10.2015 № 741, 20.02.2016 № 104, 26.05.2016 № 354, 09.11.2016 № 832, 26.05.2017 № 311, 26.03.2018 № 174, 10.09.2018 № 763, 17.06.2019 № 495, 16.09.2019 № 837, 25.12.2019 № 1201, 01.06.2020 № 451, 09.09.2020 № 814, 25.03.2021 № 169, 17.06.2022 № 577, 18.09.2023 № 1150, 31.05.2024 №390 карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән), «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2014 елның 26 декабрендәге 7132 номерлы карары |
| Программаның муниципаль заказчысы | Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты |
| Программаны төп эшләүчеләр | Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты,<br>Тукай муниципаль районында коррупциягә каршы тору комиссиясе |
| Программаның максаты | Коррупция сәбәпләрен ачыклау һәм бетерү (коррупцияне профилактикалау), коррупциягә комачаулаучы шартлар тудыру, җәмгыятьтә коррупциягә карата түземсезлек формалаштыру |
| Программаның бурычлары | 1. Коррупциягә каршы тору коралларын һәм механизмнарын, шул исәптән хокукый һәм оештыру механизмнарын камилләштерү;<br>2. Норматив хокукый актларда һәм норматив хокукый актлар проектларында коррупциягә каршы экспертиза үткәрү аша коррупциягә каршы факторларны ачыклау һәм бетерү, норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү өчен шартлар тудыру.<br>3. Мониторинг тикшеренүләре аша коррупция торышын бәяләү. |

<table>
<tr><td></td><td>4. Коррупциягә каршы укытуны оештыру һәм коррупциягә каршы пропаганданы гамәлгә ашыру, коррупциягә каршы торуга кадрлар, матди, мәгълүмати һәм гражданлык җәмгыятенең башка ресурсларын җәлеп итү.<br>5. Халык өчен муниципаль органнар эшчәнлегенең ачыклыгын, уңайлылыгын тәэмин итү, аларның гражданлык җәмгыяте белән элемтәсен ныгыту, җәмәгатьчелекнең коррупциягә каршы активлыгын стимуллаштыру.<br>Муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алуны гамәлгә ашырганда ачыклык, намуслы конкуренция һәм объективлыкны тәэмин итү.<br>7. Эшмәкәрлеккә (бизнес - структурага) административ басымның эзлекле кимүе.<br>8. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы җирле үзидарә органының хокук саклау органнары белән үзара хезмәттәшлек нәтиҗәлелеген арттыру.<br>9. Көнкүреш коррупциясен киметү буенча чараларны көчәйтү.<br>10. Муниципаль хезмәткәрләрнең коррупциягә каршы тәртибен стимуллаштыру.<br>11. Коррупциягә каршы укытуны оештыру һәм коррупциягә каршы пропаганданы гамәлгә ашыру, коррупциягә каршы торуга кадрлар, матди, мәгълүмати һәм гражданлык җәмгыятенең башка ресурсларын җәлеп итү.<br>12. Гражданнарда коррупциягә тискәре мөнәсәбәт формалаштыру</td></tr>
<tr><td>Программаны гамәлгә ашыру сроклары һәм этаплары</td><td>I этап: 2015 - 2023 еллар;<br>II этап: 2024 - 2027 еллар</td></tr>
<tr><td>Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп программаны финанслау күләме</td><td>Программаны Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы бюджеты акчалары хисабына финанслауның гомуми күләме 330 мең сум тәшкил итә, шул исәптән:
<table>
<tr><td>Ел</td><td>Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы бюджеты акчалары (мең сум)</td></tr>
<tr><td>2015</td><td>20,0</td></tr>
<tr><td>2016</td><td>20,0</td></tr>
<tr><td>2017</td><td>20,0</td></tr>
<tr><td>2018</td><td>20,0</td></tr>
<tr><td>2019</td><td>20,0</td></tr>
<tr><td>2020</td><td>20,0</td></tr>
<tr><td>2021</td><td>20,0</td></tr>
<tr><td>2022</td><td>20,0</td></tr>
<tr><td>2023</td><td>20,0</td></tr>
</table></td></tr>
</table>

| | |
|---|---|
| | 2024 — 50,0<br>2025 — 50,0<br>2026 — 50,0<br>2027 — 50,0<br>Барлыгы — 380,0<br>Искәрмә: финанслау күләме фаразлау характерында һәм Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы бюджеты мөмкинлекләрен исәпкә алып ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш |
| Программаның максатларын һәм бурычларын тормышка ашыруның көтелгән ахыргы нәтиҗәләре (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм программаның бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | Программаны гамәлгә ашыру нәтиҗәләре буенча 2026 ел ахырына түбәндәге нәтиҗәләргә ирешү көтелә:<br>эчке контроль һәм коррупциягә каршы механизмны кадрлар сәясәтенә керткән Тукай муниципаль районы җирле үзидарә органнарының өлеше, 100% ка җитәчәк;<br>проектларын эшләү стадиясендә коррупциягә каршы экспертиза үткәрелгән норматив хокукый актларның өлеше, 100% ка җитәчәк;<br>социологик сораштырулар оештыруга муниципаль бирем 100% үтәләчәк;<br>квалификациясен күтәргән муниципаль хезмәткәрләр өлеше ел саен 33% тан да ким булмаячак;<br>коррупциягә каршы тору эшчәнлеген камилләштерү мәсьәләләре буенча методик материаллар белән җирле үзидарә органнарының 100% тәэмин ителәчәк;<br>алар белән коррупциягә каршы чаралар уздырылган муниципаль хезмәткәрләр һәм муниципаль оешмалар хезмәткәрләре өлеше кимендә 50% тәшкил итәчәк;<br>гражданнарның муниципаль хезмәтләр күрсәтү сыйфатыннан канәгатьлек дәрәҗәсе кимендә 90% тәшкил итәчәк;<br>районда «бер тәрәзә» принцибы буенча дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр алу мөмкинлеге булган гражданнарның өлеше, шул исәптән дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күп функцияле үзәгендә, кимендә 90% тәшкил итәчәк;<br>законнар һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән билгеләнгән таләпләр нигезендә үз рәсми сайтларын мәгълүмат белән тутыруны тәэмин итүче Тукай муниципаль районы җирле үзидарә органнарының өлеше кимендә 90% тәшкил итәчәк;<br>Тукай муниципаль районы җирле үзидарә органнарының муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алуны оештыру һәм үткәрү өлкәсендә |

| | |
|---|---|
| | эшчәнлекнең ачыклыгын тәэмин итүче өлеше кимендә 100% булачак;<br>коррупция ситуациясенә эләккән эшмәкәрләр өлеше (Татарстан Республикасы Социаль-икътисадый мониторинг комитеты үткәргән социологик тикшеренүләр мәгълүматлары буенча) 13,7% тан артмаячак;<br>Программада каралган контроль тикшерүләрнең тулылыгы кимендә 100% булачак;<br>Тукай муниципаль районында яшәүчеләрнең үз проблемасын хәл итү өчен вакыт яки мөмкинлекләр булмау сәбәпле коррупцияле килешүгә керүче өлеше (Татарстан Республикасы социаль-икътисадый мониторинг комитеты үткәргән социологик тикшеренүләр мәгълүматлары буенча) 21,5% тан артмаячак;<br>белем бирү оешмаларында законсыз акча җыю очракларында гамәлләр турында белешмәләр алган мәктәпкәчә һәм мәктәп яшендәге балаларның ата-аналары өлеше кимендә 100% булачак;<br>муниципаль хезмәтнең абруен күтәрүгә юнәлтелгән чаралар ел саен үткәреләчәк;<br>муниципаль хезмәткә беренче тапкыр кергән һәм махсус уку үткән хезмәткәрләр саны, беренче тапкыр муниципаль хезмәткә кергәннәрнең гомуми санынннан ким дигәндә 90% тәшкил итәчәк;<br>вазыйфаларына коррупциягә каршы торуда катнашу кергән, махсус квалификация күтәргән хезмәткәрләр саны, кимендә 50% булачак;<br>муниципаль хезмәткәрләр, муниципаль районнарда эшләүче иҗтимагый советлар әгъзалары санынннан үткәрелгән индивидуаль чаралар саны кимендә 50% булачак;<br>муниципаль норматив хокукый актларның проектларын эшләү стадиясендә коррупциягә каршы экспертизага үткәрелгән өлеше, 100 процентка җитәчәк;<br>гражданнарның муниципаль хезмәтләр күрсәтү сыйфатыннан канәгатьлек дәрәҗәсе кимендә 90 процент тәшкил итәчәк;<br>булу урыны буенча «бер тәрәзә «принцибы буенча муниципаль хезмәтләр алу мөмкинлеге булган гражданнарның өлеше, шул исәптән муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләрендә дә, кимендә 90 процент тәшкил итәчәк |
| Россия Федерациясенең милли үсеш максатлары, «2030 елга кадәр Татарстан | «Россия Федерациясенең милли куркынычсызлык стратегиясе турында» Россия Федерациясе Президентының 2021 елның 2 июлендәге 400 номерлы Указы белән расланган Россия Федерациясенең милли куркынычсызлык стратегиясе;<br>Стратегия-2030; |

| | |
|---|---|
| Республикасының социаль-икътисадый үсеше стратегиясен раслау турында» 2015 елның 17 июнендәге 40-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән расланган 2030 елга кадәр Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеше стратегиясе максатлары (алга таба – Стратегия-2030) Россия Федерациясе дәүләт программасы, Татарстан Республикасының дәүләт программасы белән бәйләнеше | «2021-2024 елларга коррупциягә каршы торуның милли планы турында» Россия Федерациясе Президентының 2021 елның 16 августындагы 478 номерлы Указы белән расланган 2021-2024 елларга коррупциягә каршы торуның милли планы;<br>Россия Федерациясе Фән һәм югары белем министрлыгының 2021 елның 14 декабрендәге 475-р номерлы күрсәтмәсе белән расланган 2021-2024 елларга халыкны коррупциягә каршы агарту буенча программа;<br>«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтне үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасы;<br>«Татарстан Республикасының коррупциягә каршы сәясәтен гамәлгә ашыру» Татарстан Республикасы дәүләт программасы |

## I. ПРОГРАММАНЫҢ ГОМУМИ ХАРАКТЕРИСТИКАСЫ

Коррупция дәүләт һәм җәмгыятьнең социаль-икътисади үсешенә тискәре йогынты ясый, конкурентлыкка сәләтле икътисадны формалаштыруда киртә булып тора, халыкның иминлеген арттыруга, гражданлык җәмгыятенең үсешенә комачаулый. Шуңа бәйле рәвештә соңгы еллар Татарстан Республикасында һәм, Тукай муниципаль районында да, коррупциягә каршы тору чараларының активлашуы, барлык дәрәҗәләрдә нормалар төзү һәм хокук куллану эшен камилләштерү белән характерлана.

Әлеге Программа «Татарстан Республикасында коррупциягә каршы көрәш турында» 2006 елның 4 маендагы 34-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 9 статьясын гамәлгә ашыру йөзеннән, «Татарстан Республикасының коррупциягә каршы сәясәтен гамәлгә ашыру» Татарстан Республикасы дәүләт программасын исәпкә алып эшләнде.

Программа федераль һәм республика дәрәҗәсендә гамәлгә ашырыла торган коррупциягә каршы чаралар системасы белән концептуаль бәйле һәм муниципаль дәрәҗәдә коррупциягә каршы эшне оештыруда программа-максатлы ысулны куллану алшартларын булдыра.

## II. ПРОГРАММАНЫҢ ӨСТЕНЛЕКЛӘРЕ, МАКСАТЛАРЫ ҺӘМ ТӨП БУРЫЧЛАРЫ. ПРОГРАММАНЫҢ КӨТЕЛГӘН АХЫРГЫ НӘТИҖӘЛӘРЕН ТАСВИРЛАУ, АНЫ ГАМӘЛГӘ АШЫРУ СРОКЛАРЫ ҺӘМ ЭТАПЛАРЫ

Программаның өстенлекләре «2030 елга кадәр Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш стратегиясен раслау турында» 2015 елның 17 июнендәге 40-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән расланган 2030 елга кадәр Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үстеш стратегиясенә (алга таба – Стратегия-2030), Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясенең милли иминлек стратегиясе турында» 2021 елның 2 июлендәге 400 номерлы Указы белән расланган Россия Федерациясенең милли куркынычсызлык стратегиясенә (алга таба Россия Федерациясенең милли куркынычсызлык стратегиясе), «2021-2024 елларга коррупциягә каршы торуның милли планы турында» Россия Федерациясе Президентының 2021 елның 16 августындагы 478 номерлы Указы белән расланган 2021-2024 елларга коррупциягә каршы торуның милли планына туры килә.

Программа коррупция сәбәпләрен ачыклау һәм бетерү (коррупцияне профилактикалау), коррупциягә комачаулачы шартлар тудыру, җәмгыятьтә коррупциягә карата түземсезлек формалаштыруга юнәлтелгән.

Программаның максатлары булып тора:

1 максат: коррупциянең сәбәпләрен ачыклау һәм бетерү (коррупцияне профилактикалау), җирле үзидарә органнарын 100 процент җәлеп итүне тәэмин итү белән характерлана (коррупциягә каршы оештыру һәм хокукый чаралар, шул исәптән кадрлар сәясәтендә эчке контроль һәм коррупциягә каршы механизм кабул ителгән).

2 максат: коррупциягә комачаулаучы шартлар тудыру, ул түбәндәге күрсәткечләргә ирешү белән характерлана:

- закон чыгару һәм башка норматив хокукый актларның, шулай ук

коррупциягә каршы экспертиза үткән норматив хокукый актлар проектларының өлешен арттыру;

- коррупциягә каршы чаралар уздырылган муниципаль хезмәткәрләр өлешен арттыру.

3 максат: җәмгыятьтә коррупциягә карата түземсезлек формалаштыру, ул коррупция ситуациясенә эләккән гражданнарның коррупция килешүенә керүдән баш тарткан өлеше арту белән характерлана.

«Коррупция сәбәпләрен ачыклау һәм бетерү (коррупцияне профилактикалау)» максатына ирешү өчен түбәндәге бурычлар хәл ителә:

коррупциягә каршы тору коралларын һәм механизмнарын, шул исәптән хокукый һәм оештыру механизмнарын камилләштерү;

эшмәкәрлеккә (бизнес-структураларга) административ басымны эзлекле киметү;

җирле үзидарә органнарының хокук саклау органнары белән үзара хезмәттәшлегенең нәтиҗәлелеген арттыру;

көнкүреш коррупциясен киметү буенча чараларны көчәйтү.

«Коррупциягә комачаулаучы шартлар тудыру» максатына ирешү өчен түбәндәге бурычлар хәл ителә:

коррупциягә каршы экспертиза үткәрү аша норматив хокукый актларда һәм норматив хокукый актлар проектларында коррупциячел факторларны ачыклау һәм бетерү;

коррупциягә каршы укытуны оештыру һәм коррупциягә каршы пропаганданы гамәлгә ашыру, коррупциягә каршы торуга кадрлар, матди, мәгълүмати һәм гражданлык җәмгыятенең башка ресурсларын җәлеп итү;

халык өчен гавами хакимият органнары эшчәнлегенең ачыклыгын, уңайлыгын тәэмин итү, аларның гражданлык җәмгыяте белән элемтәләрен ныгыту, җәмәгатьчелекнең коррупциягә каршы активлыгын стимуллаштыру;

дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алуны гамәлгә ашырганда ачыклык, намуслы конкуренция һәм объективлыкны тәэмин итү.

«Җәмгыятьтә коррупциягә карата түземсезлек формалаштыру» максатына ирешү өчен түбәндәге бурычлар хәл ителә:

Тукай муниципаль районында коррупция торышын бәяләү;

норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрүгә экспертлар берләшмәсен җәлеп итү;

гражданнарда коррупциягә тискәре мөнәсәбәт формалаштыру.

Программаны гамәлгә ашыру нәтиҗәләре буенча 2026 ел ахырына түбәндәге нәтиҗәләргә ирешү көтелә:

эчке контроль һәм коррупциягә каршы механизмны кадрлар сәясәтенә керткән Тукай муниципаль районы җирле үзидарә органнарының өлеше 100% ка җитәчәк;

проектларын эшләү стадиясендә коррупциягә каршы экспертиза үткәрелгән норматив хокукый актларның өлеше 100% ка җитәчәк;

социологик сораштырулар оештыруга муниципаль бирем 100% үтәләчәк;

квалификациясен күтәргән муниципаль хезмәткәрләр өлеше ел саен 33% тан да ким булмаячак;

коррупциягә каршы тору эшчәнлеген камилләштерү мәсьәләләре буенча методик материаллар белән җирле үзидарә органнары 100% тәэмин ителәчәк;

алар белән коррупциягә каршы чаралар уздырылган муниципаль хезмәткәрләр һәм муниципаль оешмалар хезмәткәрләре өлеше кимендә 50% тәшкил итәчәк;

гражданнарның муниципаль хезмәтләр күрсәтү сыйфатыннан канәгатьлек дәрәҗәсе кимендә 90% тәшкил итәчәк;

районда «бер тәрәзә» принцибы буенча дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр алу мөмкинлеге булган гражданнарның өлеше, шул исәптән дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күп функцияле үзәгендә, кимендә 90% тәшкил итәчәк;

законнар һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән билгеләнгән таләпләр нигезендә үз рәсми сайтларын мәгълүмат белән тутыруны тәэмин итүче Тукай муниципаль районы җирле үзидарә органнарының өлеше кимендә 90% тәшкил итәчәк;

Тукай муниципаль районы җирле үзидарә органнарының муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алуны оештыру һәм үткәрү өлкәсендәге эшчәнлекнең ачыклыгын тәэмин итүче өлеше кимендә 100% булачак;

коррупция ситуациясенә эләккән эшмәкәрләр өлеше (Татарстан Республикасы Социаль-икътисадый мониторинг комитеты үткәргән социологик тикшеренүләр мәгълүматлары буенча) 13,7% тан артмаячак;

Программада каралган контроль тикшерүләрнең тулылыгы кимендә 100% булачак;

Тукай муниципаль районында яшәүчеләрнең үз проблемасын хәл итү өчен вакыт яки мөмкинлекләр булмау сәбәпле коррупцияле килешүгә керүче өлеше (Татарстан Республикасы Социаль-икътисадый мониторинг комитеты үткәргән социологик тикшеренүләр мәгълүматлары буенча) 21,5% тан артмаячак;

белем бирү оешмаларында законсыз акча җыю очракларында гамәлләр турында белешмәләр алган мәктәпкәчә һәм мәктәп яшендәге балаларның ата-аналары өлеше кимендә 100% булачак;

муниципаль хезмәтнең абруен күтәрүгә юнәлтелгән чаралар ел саен үткәреләчәк;

муниципаль хезмәткәрләрнең гомуми саныннан мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау һәм җайга салу турында таләпләрне үтәү буенча үткәрелгән анализлар/тикшерүләр саны; мәнфәгатьләр конфликты белән бәйле хокук бозу кылган муниципаль хезмәткәрләр саныннан мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау һәм җайга салу турында таләпләрне үтәмәгән өчен дисциплинар җаваплылыкка тартылганнар саны;

муниципаль хезмәткә беренче тапкыр кергән һәм махсус уку үткән хезмәткәрләр саны беренче тапкыр муниципаль хезмәткә кергәннәрнең гомуми саныннан ким дигәндә 90% тәшкил итәчәк;

вазыйфаларына коррупциягә каршы торуда катнашу кергән, махсус квалификация күтәргән хезмәткәрләр саны кимендә 50% булачак;

муниципаль хезмәткәрләр, муниципаль районнарда эшләүче иҗтимагый советлар әгъзалары саныннан үткәрелгән индивидуаль чаралар саны кимендә 50% булачак;

муниципаль норматив хокукый актларның проектларын эшләү стадиясендә коррупциягә каршы экспертизага үткәрелгән өлеше 100 процентка җитәчәк;

гражданнарның муниципаль хезмәтләр күрсәтү сыйфатыннан канәгатьлек дәрәҗәсе кимендә 90 процент тәшкил итәчәк;

булу урыны буенча «бер тәрәзә «принцибы буенча муниципаль хезмәтләр алу мөмкинлеге булган гражданнарның өлеше, шул исәптән муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләрендә, кимендә 90 процент тәшкил итәчәк;

Программаны гамәлгә ашыру срогы: 2015 - 2027 еллар.

I этап: 2015 - 2023 еллар;

II этап: 2024 - 2027 еллар.

Төп максатлар, бурычлар, нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, шулай ук программада каралган чараларны финанслау күләме программага кушымтада күрсәтелгән.

## III. ПРОГРАММАНЫ РЕСУРСЛАР БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮНЕ НИГЕЗЛӘҮ

Программаны финанслау күләме фараз характерында һәм Тукай муниципаль районы бюджеты мөмкинлекләрен исәпкә алып ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш.

Моннан тыш, Программа чараларын гамәлгә ашыруга чараларны башкаручыларның төп эшчәнлеген финанслауга бүлеп бирелгән акчаларны куллану күздә тотыла.

## IV. ПРОГРАММАНЫ ГАМӘЛГӘ АШЫРУ МЕХАНИЗМЫ

Программаның үтәлешен планлаштыру, үзара хезмәттәшлек итү, координацияләү һәм гомуми контрольдә тотуны Тукай муниципаль районында коррупциягә каршы тору комиссиясе гамәлгә ашыра, ул ел саен Программа чараларының максатчан күрсәткечләрен һәм чыгымнарын, программаны гамәлгә ашыру механизмын һәм башкаручылар составын төгәлләштерә, Тукай муниципаль районы җирле үзидарә органнарыннан, чараларны үтәү өчен җаваплы учреждениеләрдән һәм оешмалардан Программа үтәлеше барышы турында мәгълүмат сорый.

Тиешле чараларны гамәлгә ашыру өчен җаваплы Программаны башкаручылар Тукай муниципаль районы Башлыгына – Тукай муниципаль районында коррупциягә каршы тору комиссиясе рәисенә квартал саен хисап чорыннан соң киләсе айның 1 числосына кадәр чараларның үтәлеше һәм чараларны башкаручыларга бүлеп бирелгән үзләштерелгән акчалар турында мәгълүмат тапшыралар.

Еллык хисап Тукай муниципаль районы Башлыгына – Тукай муниципаль районында коррупциягә каршы тору комиссиясе рәисенә бирелә һәм түбәндәгеләрне үз эченә ала:

хисап чорында ирешелгән конкрет нәтиҗәләр;

билгеләнгән срокларда башкарылган һәм башкарылмаган (сәбәпләрен күрсәтеп) чаралар исемлеге;

Программаны гамәлгә ашыру барышына йогынты ясаган факторларны анализлау;

чараларны үтәү өчен акча куллану турында мәгълүмат;

башка мәгълүмат.

Программага үзгәрешләр кертү Программа чараларының җаваплы башкаручысы инициативасы һәм килешүе буенча яисә Тукай муниципаль районы Башлыгы – Тукай муниципаль районында коррупциягә каршы тору комиссиясе рәисе йөкләмәләрен үтәү йөзеннән, билгеләнгән таләпләргә туры китереп башкарыла.

## V. ПРОГРАММАНЫҢ СОЦИАЛЬ-ИКЪТИСАДИ НӘТИҖӘЛЕЛЕГЕН БӘЯЛӘҮ

Программаның гомуми нәтиҗәлелеге 2026 елга планлаштырылган максатчан параметрларга ирешү дәрәҗәсе, каралган чараларны билгеләнгән срокларда гамәлгә ашыру буенча бәяләнә. Программаның нәтиҗәлелеген бәяләү өчен социологик тикшеренү нәтиҗәләре, шулай ук агымдагы хисап материаллары кулланыла.

2027 елга Программа чараларын гамәлгә ашыру мөмкинлек бирәчәк:

коррупциягә каршы тору өлкәсендә муниципаль идарәнең нәтиҗәлелеген арттырырга;

Тукай муниципаль районында җирле үзидарә органнарының коррупциягә каршы эшчәнлегендә җәмәгатьчелекнең ролен арттырырга;

җәмгыятьтә коррупциягә карата түземсез мөнәсәбәт формалаштырырга.

Программаның социаль эффекты гражданнарның конституцион хокукларын һәм ирекләрен тулырак тормышка ашыруда бәяләнә.

Программаның үзенчәлеген исәпкә алып, турыдан-туры икътисади нәтиҗәлелекне билгеләү мөмкин түгел, чөнки программа чаралары гадәти статистик үлчәүләргә бирелми һәм кыйммәт бәяләмәсендә белдерелми. Шул ук вакытта Программа чараларын гамәлгә ашыруның турыдан-туры аңа карамаган икътисади эффекты Тукай муниципаль районының уңай имиджын формалаштыру, шул исәптән инвестицион җәлеп итүчәнлек, эшмәкәрлек активлыгын арттыру, Тукай муниципаль районы җирле үзидарә органнарында коррупция күренешләре белән бәйле бюджет югалтуларын киметү нәтиҗәсендә күзәтелергә мөмкин.

Программада эшчәнлек нәтиҗәләрен характерлаучы индикаторлар һәм күрсәткечләр системасы кулланыла. Программаны гамәлгә ашыруның бөтен чорында нәтиҗәлелеген бәяләү 2026 елга Программаны үтәү нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары буенча күрсәткечләргә ирешүне исәпкә алып үткәрелә.

**«2015-2027 елларга Тукай муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру» муниципаль программасының максатлары, бурычлары, индикаторлары**

| | | | | | Индикаторның төп зурлыгы | | Еллар буенча индикаторның планлы зурлыгы | | | | Финанслау (мең сум) финанслау чыганагын күрсәтеп | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| № | Чараның исеме | Гамәлгә ашыру чоры | Индикаторның исеме | Индика-торны үлчәү берәмлеге | зурлык | ел | 2024 | 2025 | 2026 | 2027 | 2024 | 2025 | 2026 | 2027 |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 8 | 9 | 10 | 11 |
| 1. | Тукай муниципаль районында коррупциягә каршы көрәш, шул исәптән хокукый һәм оештыру инструментларын механизмнарын камилләштерү | | | | | | | | | | | | | |
| 1.1. | Федераль, республика законнарын үтәү һәм Татарстан Республикасында коррупциягә каршы гамәлдәге нормаларны куллану практикасын гомумиләштерү нигезендә коррупциягә каршы тору өлкәсендә Тукай районы җирле үзидарә органнарының муниципаль норматив хокукый актларын эшләү һәм Тукай районы җирле үзидарә органнарының гамәлдәге муниципаль норматив хокукый актларына үзгәрешләр кертү (кирәк булганда гамәлгә ашырыла) | 2024-2027 еллар | Коррупциягә каршы көрәш өлкәсендә федераль һәм республика законнарына туры китерелгән Тукай районы җирле үзидарә органнарының муниципаль норматив хокукый актлары өлеше | процентлар | 100 | 2023 | 100 | 100 | 100 | 100 | | | | |
| 1.2. | «Федераль дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы граждannар һәм федераль дәүләт хезмәткәрләре тарафыннан тапшырыла торган | 2024-2027 еллар | Коррупциягә каршы торуның кабул ителгән оештыру һәм хокукый чараларының тулылыгы, шул исәптән эчке контроль һәм | процентлар | 100 | 2023 | 100 | 100 | 100 | 100 | | | | |

| | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | мәгълүматларның дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү һәм федераль дәүләт хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәве турында» Россия Федерациясе Президентының 2009 елның 21 сентябрендәге 1065 номерлы Указы, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан тапшырыла торган мәгълүматларның дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәве турында» Татарстан Республикасы Президентының 2010 елның 1 ноябрендәге ПУ-711 номерлы Указы нигезендә Тукай районы җирле үзидарә органнарының коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча бүлекчәләренең (коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы кадрлар хезмәте вазыйфаи затларының) нәтиҗәле эшләвен тәэмин итү | | кадрлар сәясәтендә коррупциягә каршы механизм | | | | | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1.3. | Тукай районы муниципаль хезмәткәрләре гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган коррупция куркынычларын бәяләү һәм коррупция куркынычы белән бәйле булган муниципаль хезмәт вазыйфалары исемлегенә төгәллекләр кертү (кирәк булганда) | 2024-2027 еллар | | | | | | | | | | | |
| 1.4. | Тукай районының коррупциягә каршы тору эшен координацияләү комиссиясенең еллык эш планнарын раслау һәм үтәү | 2024-2027 еллар | | | | | | | | | | | |
| 1.5. | Тукай районы муниципаль хезмәткәрләренең шәхси эшләренә анализ ясау һәм андый хезмәткә кергәндә тапшырыла торган анкеталардагы, аларның туганнары һәм кардәшләре (абыйларының һәм апаларының тормыш иптәшләре, ирләренең яисә хатыннарының абыйлары һәм апалары) турында белешмәләрне мөмкин булган мәнфәгатьләр конфликтын ачыклау максатында актуальләштерү | 2024-2027 еллар | Тукай районы җирле үзидарә органнары хезмәткәрләре тарафыннан коррупциягә каршы тору өлкәсендә закон таләпләрен үтәүне тәэмин итүгә юнәлтелгән үткәрелгән чараларның бер елга планлаштырылган гомуми саныннан өлеше | процентлар | 100 | 2023 | 100 | 100 | 100 | 100 | | | |
| 1.6. | Тукай районы муниципаль хезмәткәрләренең муниципаль хезмәт турында законнарда каралган чикләүләрне һәм тыюларны | 2024-2027 еллар | | | | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | үтәвен, шул исәптән эшкуарлык эшчәнлегендә катнашуын «Юридик затларның бердәм дәүләт реестры» һәм «Шәхси эшмәкәрләрнең бердәм дәүләт реестры» Федераль салым хезмәтенең мәгълүмат базаларын, башка мәгълүмат системаларын кулланып тикшерү (кимендә елга бер тапкыр) | | | | | | | | | | | | | |
| 1.7. | Муниципаль вазыйфаларны, Тукай районы муниципаль хезмәте вазыйфаларын биләүче затларның коммерцияле һәм коммерциясез оешмалар белән идарә итүдә катнашуына мониторинг үткәрү | 2024-2027 еллар | | | | | | | | | | | | |
| 1.8. | «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 13.3 статьясында каралган чаралар күрү бурычын үтәүне, тәэмин итү максатыннан, шул исәптән коррупцияне кисәтү, оешмаларның мәнфәгатьләр конфликтын ачыклау, кисәтү һәм җайга салу буенча Тукай районы җирле үзидарә органнарына караган оешмалар белән эш алып бару | 2024-2027 еллар | | | | | | | | | | | | |
| 1.9. | Коррупциягә каршы тору максатларында билгеләнгән тыюларны, чикләүләрне һәм таләпләрне үтәмәүнең һәр очрагында законнарда | 2024-2027 еллар | | | | | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | каралган юридик җаваплылык чараларын куллануны контрольдә тотуны гамәлгә ашыру | | | | | | | | | | | | | |
| 1.10. | Тукай районы муниципаль хезмәте вазыйфаларын биләүче затларның коррупциягә каршы тору турында Россия Федерациясе законнарының мәнфәгатьләр конфликтын булдырмауга һәм җайга салуга кагылышлы таләпләрен үтәне, шул исәптән аларны үтәмәү очрагында, андый затларны җаваплылыкка тартуны контрольдә тотуны гамәлгә ашыру | 2024-2027 еллар | | | | | | | | | | | | |
| 2. | Тукай районы җирле үзидарә органнары тарафыннан эшләнгән муниципаль норматив хокукый актлар проектларында коррупциягә каршы экспертиза үткәрү юлы белән коррупциягә каршы факторларны ачыклау һәм бетерү, Тукай районы җирле үзидарә органнары тарафыннан эшләнә торган норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү өчен шартлар тудыру | | | | | | | | | | | | | |
| 2.1. | Тукай районы җирле үзидарә органнары тарафыннан эшләнгән муниципаль норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү өчен шартлар тәэмин итү һәм күрсәтелгән экспертиза үткәрү нәтиҗәләрен гомумиләштерү | 2024-2027 еллар | Тукай районы җирле үзидарә органнары тарафыннан эшләнгән муниципаль норматив хокукый актлар проектларының коррупциягә каршы экспертиза үткәрелгән өлеше | процентлар | 100 | 2023 | 100 | 100 | 100 | 100 | | | | |
| 2.2. | Тукай районы җирле үзидарә органнары тарафыннан эшләнгән муниципаль норматив хокукый актлар проектларын норматив хокукый актлар проектларын һәм аларның иҗтимагый фикер алышу нәтиҗәләрен әзерләү турында мәгълүмат | 2024-2027 еллар | | | | | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | урнаштыру өчен булдырылган рәсми сайтта урнаштыру http://tatarstan.ru/regulation | | | | | | | | | | | | | |
| 3. | Тукай муниципаль районында коррупция торышын бәяләү | | | | | | | | | | | | | |
| 3.1. | Максатчан төркемнәр арасында коррупциячел факторларга һәм гамәлгә ашырылган коррупциягә каршы чараларга тармак тикшеренүләре үткәрү һәм күрсәтелгән тикшеренүләр нәтиҗәләрен бастыру | 2024-2027 еллар | Үткәрелгән тикшеренүләр саны | шартлы берәмлек-ләр | 1 | 2023 | 1 | 1 | 1 | 1 | | | | |
| 4. | Коррупциягә каршы укытуны оештыру һәм коррупциягә каршы пропаганданы гамәлгә ашыру, коррупциягә каршы торуга гражданлык җәмгыятенең кадрлар, матди, мәгълүмати һәм башка ресурсларын җәлеп итү | | | | | | | | | | | | | |
| 4.1. | Тукай районы җирле үзидарә органнары һәм аның карамагындагы оешмалар хезмәткәрләрендә коррупциягә тискәре мөнәсәбәт формалаштыру эшен гамәлгә ашыру, шул исәптән чикләүләрне, тыюларны үтәү, шулай ук коррупциягә каршы тору максатларында билгеләнгән бурычларны үтәү буенча, әлеге эшкә коррупциягә каршы торуда катнашучы иҗтимагый советларны, иҗтимагый берләшмәләрне һәм гражданлык җәмгыятенең башка институтларын җәлеп итеп, оештыру, аңлату һәм башка чаралар күрү | 2024-2027 еллар | Тукай районы җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең коррупциягә каршы чараларга җәлеп ителгән өлеше | процентлар | 50 | 2023 | 100 | 100 | 100 | 100 | | | | |
| 4.2. | Тукай районы Иҗтимагый советы утырышларында коррупциягә каршы тору | 2024-2027 еллар | | | | | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | программаларын гамәлгә ашыру турында хисапларны карау | | | | | | | | | | | | |
| 4.3. | Тукай районы муниципаль хезмәткәрләрен квалификация күтәрү программалары буенча укытуны белем бирү программаларына коррупциягә каршы тематика буенча дисциплиналар кертеп оештыру | 2024-2027 еллар | Коррупциягә каршы тематика буенча дисциплиналар кертелгән программалар буенча квалификация күтәрү үткән Тукай районы муниципаль хезмәткәрләренең өлеше | процентлар | 33 | 2023 | 33 | 33 | 33 | 33 | | | |
| 4.4 | Районның мәгариф оешмаларында коррупциягә каршы юнәлештә конкурслар үткәрү | 2024-2027 еллар | Коррупциягә каршы укытуга һәм коррупциягә каршы пропагандага юнәлдерелгән үткәрелгән чараларның өлеше, бер елга планлаштырылган гомуми саннан, процентлар | Районда ел саен уздырыла торган акцияләр саны | 4 | 2023 | 4 | 4 | 4 | 4 | 20,0 | 20,0 | 20,0 | 20,0 |
| 4.5. | Җирле үзидарә органнары һәм муниципаль учреждениеләр өчен коррупциягә каршы темага күрсәтмә әсбаплар әзерләү | 2024-2027 еллар | | Әзерләнгән агитация материалы саны | 50 | 2023 | 60 | 70 | 80 | 80 | 30,0 | 30,0 | 30,0 | 30,0 |
| 5. | Тукай муниципаль районы җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең ачыклыгын, гражданнарга уңайлыгын тәэмин итү, гражданлык җәмгыяте белән хезмәттәшлек итү, җәмәгатьчелекнең коррупциягә каршы активлыгын стимуллаштыру | | | | | | | | | | | | | |
| 5.1. | Тукай районы җирле үзидарә органнарында гражданнарга үзләренә билгеле булган коррупция фактлары, аларны кылуга ярдәм итүче сәбәпләр һәм шартлар турында хәбәр итәргә мөмкинлек бирә торган ышаныч телефоннары, кайнар | 2024-2027 еллар | Тукай районы җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең ачыклыгын, гражданнар өчен уңайлылыгын тәэмин итүгә, гражданлык җәмгыяте белән хезмәттәшлеккә, | процентлар | 100 | 2023 | 100 | 100 | 100 | 100 | | | | |

| | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | линияләр, интернет-кабул итү бүлмәләре, башка мәгълүмат каналларының эшләвен тәэмин итү | | җәмәгатьчелекнең коррупциягә каршы активлыгын стимуллаштыруга юнәлдерелгән үткәрелгән чаралар өлеше | | | | | | | | | | | |
| 5.2. | Тукай районы вазыйфаи затларының массакүләм мәгълүмат чараларында урнаштырылган һәм гражданнар һәм юридик затларның килгән мөрәҗәгатьләрендә булган коррупция күренешләре турында мәгълүматны мониторинглау, аның нәтиҗәләрен квартал саен гомумиләштерү һәм коррупциягә каршы тору комиссияләре, Тукай районының коррупциягә каршы тору буенча эшне координацияләү комиссиясе утырышларында карау | 2024-2027 еллар | | | | | | | | | | | | |
| 5.3. | Мәгълүмат стендларын, Тукай районы рәсми сайтының «Коррупциягә каршы тору» бүлеген рәсмиләштерү һәм актуальләштерү, коррупциягә каршы эчтәлекле мәгълүмат бирүнең башка формалары | 2024-2027 еллар | | | | | | | | | | | | |
| 5.4. | Тормыш эшчәнлегенең социаль-икътисадый тармакларында коррупция күренешләре турында гражданнарның мөрәҗәгатьләренә мониторинг үткәрү | 2024-2027 еллар | | | | | | | | | | | | |
| 6. | Тукай муниципаль районының муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алуны гамәлгә ашырганда ачыклык, намуслы конкуренция һәм объективлыкны тәэмин итү | | | | | | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 6.1. | Муниципаль ихтыяҗлар өчен товарлар (эшләр, хезмәтләр) сатып алуны гамәлгә ашырганда коррупция дәрәҗәсен киметүгә ярдәм итүче чараларны гамәлгә ашыру, шул исәптән сатып алуларның ачыклыгын һәм уңайлыгын тәэмин итү буенча чаралар үткәрү, шулай ук сатып алуларда катнашучыларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү буенча чараларны гамәлгә ашыру | 2024-2027 еллар | Контроль органнар тарафыннан сатып алу объектын тасвирлау кагыйдәләрен һәм контрактның башлангыч максималь бәясен формалаштыру кагыйдәләрен бозган өчен Тукай районы вазыйфаи затын административ җаваплылыкка тарту турында карар чыгарылган сатып алулар өлеше* | шартлы берәмлек-ләр | 0 | 2023 | 30 | 30 | 30 | 30 | | | | |
| | **БАРЛЫГЫ** | | | | | | | | | | **50,0** | **50,0** | **50,0** | **50,0** |

*Күрсәткечнең зурлыгы ≤ 30 билгесе белән.